СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**«27» ноябрь 2025 ел.** **№ 2**

**Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 19 ноябренә 19 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 75 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 150 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен күперләрне һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен төзекләндерү (материаллар сатып алу);

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге, автомобиль юлларын төзү,ремонтлау, тоту (Чулпан авылының Тимер юл урамында юл полотнасын ямау юлы белән төзекләндерү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

3.Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Кәче авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендында: ТР, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гәрәев

СОВЕТ КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ